**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАБАР ЧЕРКЕНЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 ел, 1 октябрь N7

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлеге бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 17 пунктының «б» пунктчасына таянып,Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлеге Советы **карар бирә**:

1.«Татарстан Республикасы Табар Черкене авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының 2019 елның 8 ноябрендәге 127 номерлы карары белән расланган Табар Черкене авыл җирлегенең бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Җирлек советы керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм җирлек Советының бюджет турындагы карар проектын җирлек Советына керткәннән соң кабул ителгән карарларының нигезләмәләре чираттагы финанс елында, агымдагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджетына үзгәрешләр керткәндә, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә исәпкә алына.».

2.Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Табар Черкене авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

**Табар Черкене авыл**
**җирлеге Башлыгы** **Р.Х. Ибәтуллин**